**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«12» декабрь 2025 ел** **№ 164**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының 2019 елның 22 апрелендәге 263 номерлы «Теләче муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре аларга кагылмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф сеткасы таралмый торган бюджет даирәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 декабрендәге 996 номерлы карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмый торган социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне тәртипкә салу максатларында, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының 2019 елның 22 апрелендәге 263 номерлы «Теләче муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре аларга кагылмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» карарының 1 пунктының 3 абзацын (12.10.2020 № 439, 02.03.2022 № 30, 29.09.2022 № 185, 25.10.2022 № 215, 03.05.2024 № 56, 04.10.2024 № 123, 16.04.2025 № 61 карарлар редакциясендә) түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«- аерым оешмаларның җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме Теләче муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль берәмлекләрдә бюджет өлкәсенең аерым оешмасы структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи окладының күләменә бер тапкыр туры килә, ул 16 928 сум тәшкил итә;».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин